ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 15 февраля 2016 г. г. Казань № 63

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләре тәртибен раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифасын, федераль дәүләт хезмәтен башкаручы һәм башка затларның вазифадагы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгарган яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләре тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 650нче Указы белән

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләр тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар бүлеге җитәкчесенә (Т.А.Толстая) тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук хезмәт контрактлары төзелгән гражданнарны әлеге әмер белән таныштыру;

Тәртипне Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының “Коррупциягә каршы тору” мәгълүмат стендында урнаштыру.

3. Мәгълүмат бүлегенә (М.Х.Абайдуллинга) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталы Татарстан Республикасы тарифлар

буенча Дәүләт комитеты рәсми сайтына “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең “Коррупциягә каршы көрәш” бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерык аның рәсми чыгарылган көненнән алып 10 көн эчендә үз көченә керә.

5. Әлеге боерыкның үтәлеше үз күзәтчелегем астында кала.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт Комитетының 15.03.2016 елның 63 санлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләрен
хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алда – гражданлык хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты) вазифадагы бурычын үтәгәндә яклар арасында чыккан яисә чыгарга мөмкин булган бәхәсләр белән шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе мәнфәгатьләрен күрсәтүче вәкиленә (алда – рәис) хәбәр итү процедурасы регламентын билгели

2. Гражданлык хезмәткәре тарафыннан вазифадагы бурычын үтәгәндә яклар арасында чыккан яисә чыгарга мөмкин булган бәхәсләр белән шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр әлеге Тәртип кушымтасында күрсәтелгәнчә, язма формада төзелеп (алда – хәбәрнамә), рәискә җибәрелә.

3. Рәис өч көн эчендә хәбәрнамәне коррупцион яисә башка төрле хокук бозулар профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка якынча карауга җибәрә (алда – җаваплы зат).

4. Хәбәрнамәне якынча карау барышында җаваплы затның хәбәрнамә җибәргән гражданлык хезмәткәреннән күрсәтелгәннәр буенча аңлатма сорап алырга, дәүләт власте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеле тәртиптә запрослар җибәрергә хокукы бар.

5. Хәбәрнамәне якынча карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат үз аңлатмасын әзерли. Якынча карау барышында алынган хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материалларны җаваплы зат хәбәрнамәне алган көннән алып җиде көн эчендә Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм яклар бәхәсләрен көйләү буенча Комиссиясе рәисенә (алда – Комиссия) җибәрә

6. Белдерүләрне алдан карау барышында ясалган нәтиҗә һәм башка материаллар Дәүләт Комитеты рәисенә Дәүләт Комитеты Комиссиясенә белдерү кергән көннән алып җиде эш көне эчендә бирелә. Әлеге Тәртипнең 4нче пунктында күрсәтелгән запросларны җибәргән очракта, нәтиҗәләр һәм башка материаллар Дәүләт Комитеты рәисенә Комиссиягә белдерү кергән

көннән алып 45 көн эчендә бирелә. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән артмаска тиеш.

7. Хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материалларны Комиссия Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2016 елның 15 февралендәге 62нче әмере белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм яклар бәхәсләрен көйләү буенча Комиссиясе Нигезләмәсенә ярашлы рәвештә карый.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләр тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе
М.Р.Зариповка

______________________________
(вазыйфа атамасы)
______________________________
______________________________
______________________________
(Ф.И.О., адрес, телефон номеры)

вазифадагы бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр низагларын чыгара алган яисә чыгарырга мөмкин булганнар белән шәхси кызыксынуым турында
хәбәрнамә

Вазифа бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагларын чыгара алган яисә чыгарырга мөмкин булганнар белән шәхси кызыксынуым турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну тудырган сәбәпләр: ______________________________
______________________________________________________________

Үтәү барышына шәхси кызыксыну тәэсир иткән яисә тәэсир итә алган вазифадагы бурычлар:______________________________________________________
______________________________________________________________

Мәнфәгатьләр низагларын булдырмый калу яисә юкка чыгару буенча тәкъдим ителгән чаралар:
______________________________________________________________
______________________________________________________________

Татарстан Республикасы тарифлар һәм мәнфәгатьләр низагларын көйләү буенча Дәүләт Комитетының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү буенча Комиссия утырышында әлеге белдерүне караганда үзем катнашырга җыенам (җыенмыйм)(кирәклесенең астына сызарга кирәк).

| ____________ | ______________________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаны расшифровкалау) |